ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20.10.2021 ел Баулы шәһәре №187

2021-2023 елларга Татарстан
Республикасы Баулы муниципаль
районының дәүләт яшьләр сәясәтен
үстерү стратегиясен раслау турында

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында яшьләр сәясәте үсеше белән стратегик идарә итүне камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Кушымтадагы 2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының дәүләт яшьләр сәясәтен үстерү стратегиясен расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 20 октябрендәге
187 номерлы карары белән
расланган

2021-2023 елларга
Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының
дәүләт яшьләр сәясәтен үстерү
стратегиясе

## I. Гомуми нигезләмәләр

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының дәүләт яшьләр сәясәтен үстерү стратегиясе (алга таба - Стратегия) 2023 елга кадәр чорга эшләнде һәм Баулы муниципаль районы территориясендә дәүләт һәм иҗтимагый яшьләр сәясәтенең эчтәлекле нигезләрен, үзара хезмәттәшлеге механизмын һәм яшьләр сәясәтенең өстенлекле юнәлешләрен гамәлгә ашыру системасын билгели.

Хәзерге этапта яшьләр сәясәте даирәсе социаль, икътисадый, сәяси мәсьәләләр, демография, гаилә һәм торак сәясәте, мәгариф, тәрбия, фән, спорт һәм психология проблемаларының тулы бер комплексын үз эченә ала. Аларны нәтиҗәле хәл итү кеше капиталына һәм, беренче чиратта, яшьләргә инвестицияләрсез мөмкин түгел.

Яшь буынның сәяси үсешнең төп процессларына максималь керүе, демократик институтларны ныгыту, икътисадый үсешне тизләтү, инновацион технологияләр кертү, социаль әһәмиятле инициативаларны гамәлгә ашыру мөһим.

Инновацион яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру шартында гына югары заманча стандартлар нигезендә район яшьләренең нәтиҗәлелеген тәэмин итәргә мөмкин. Әлеге модельгә күчү процессын активлаштыруның төп механизмы булып Баулы муниципаль районының дәүләт яшьләр сәясәтен үстерүнең әлеге стратегиясе торырга тиеш.

14-30 яшьлек яшьләр саны кимү шартларында озак сроклы һәм урта сроклы яшьләр сәясәте күбесенчә санга бәйле максатлардан һәм бурычлардан (җәлеп ителүне арттыру, катнашучылар санын арттыру һ.б.) сыйфатка бәйле максатларга һәм бурычларга - яшьләрнең кеше капиталы зурлыгын арттыру, социаль субъект буларак яшьләрнең продуктивлыгын арттыру, яшьләр даирәсенә керә торган ресурслардан (финанс, кадрлар, матди, мәгълүмати) файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру) күчүне тәэмин итәргә тиеш. Шул ук вакытта яшьләрнең төрле яшь төркемнәренең - 14-16 яшь, 17-25 яшь, 26-30 яшь - роле һәм мәнфәгатьләре аермасын да исәпкә алырга кирәк, ягъни аның тормыш циклының төрле стадияләрендә яшьләр үсешенең максатлары һәм бурычлары үзенчәлеген.

2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең озак вакытлы социаль-икътисадый үсеш фаразына караганда, хәзерге вакытта һәм якын киләчәктә яшьләр үсешенең һәм яшьләр сәясәтенең глобаль кыенлыклары булып түбәндәгеләр кала:

Демографик үсештә тискәре тенденцияләрнең көчәюе.

Икътисадый актив яшьтә үлүчеләр санының югары дәрәҗәсе һәм туучылар санының кимүе җитди демографик проблемалар булып тора.

Яшьләрнең хокук бозу дәрәҗәсе үзгәрү.

Яшьләр арасында хокук бозу дәрәҗәсе актуаль мәсьәлә булып кала. Шул ук вакытта яшьләр тарафыннан кылына торган хокук бозулар динамикасы гомуми җинаятьчелек динамикасын кабатлый, аның яртысыннан күбрәген тәшкил итә, шул ук

вакытта җинаятьләрнең иң күп саны 18 - 24 яшь төркеменә туры килә.

Шулай итеп, кимүгә карамастан, җинаятьчелек яшьләр арасында таралган күренеш булып кала бирә.

Яшь буынның сәламәтлеген саклап калу.

Хәзерге этапта яшьләрнең сәламәтлеге - җәмгыятьнең тормыш дәрәҗәсен билгеләүче иң мөһим күрсәткечләрнең берсе. Яшьләр сәясәте позициясеннән караганда, сәламәт яшәү рәвешен, физик культураны, спортны популярлаштыру, сәламәтлеккә куркыныч тудыручы үз-үзеңне тотышны булдырмау мөһим юнәлешләр булып тора. Барыннан да элек бу наркотиклар, психотроп матдәләр, алкоголь һәм токсик матдәләр куллануга кагыла.

Яшьләрнең мәшгульлеге һәм эшкә урнашуы.

Яшьләрнең эшкә урнашу мәсьәләсе дә актуаль. Яшь белгечләргә ихтыяҗ булмауның иң киң таралган сәбәпләренең берсе - уку йортында алган һөнәрнең (белгечлекнең) икътисадның эшче көчкә ихтыяҗы структурасына туры килмәү.

Яшь гаиләләрнең проблемалары.

Анализ яшь гаиләгә институтына дәүләт ярдәме кирәклеген раслый. Шул ук вакытта сүз, барыннан да элек, гаилә яшәеше өчен уңайлы пространство булдыру һәм аның мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру турында бара.

Ике проблема аеруча актуаль булып кала:

- социаль - икътисадый, аңа матди тәэмин ителеш, торак һәм яшь ирләрне эшкә урнаштыру проблемалары керә;

- социаль - психологик, ул яшь ир белән хатынның бер-берсенә, гаилә тормышына (рольләрне, стереотипларны һәм үз-үзеңне тоту стилен алыштыру) һәм яңа туганнарга җайлашу проблемаларын үз эченә ала.

Яшь буынны заманча тәрбияләү үзенчәлекләре.

Хәзерге заман шартларында тәрбия иҗади, интеллектуаль, рухи, әхлакый һәм физик яктан үсеш алган, эш нәтиҗәләре өчен җаваплы шәхес формалаштыруда хәлиткеч роль уйный. Яшь кешенең шәхесен тәрбияләүнең заманча системасын формалаштыру өчен яңа иҗтимагый тенденцияләр нигезендә аны үстерү өчен шартлар тудыру һәм яшьләрне социальләштерүнең барлык субъектларының нәтиҗәле хезмәттәшлеген оештыру буенча актуаль мәсьәләләрне хәл итү мөһим.

## II. Җирле үзенчәлекләр характеристикасы

Баулы муниципаль районында «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының яшьләр эшләре бүлеге» МКУ эшли.

«Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының яшьләр эшләре бүлеге» МКУ составына керүче структур бүлекчәләр:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Яшьләр дөньясы» күппрофильле яшьләр үзәге муниципаль бюджет учреждениесе («Яшьләр дөньясы» КЯҮ МБУ структур бүлекчәсе «Пегас» яшүсмерләр клубы);
2. «Карлыгач» АДОДУ.

Булган ресурслар: оештыру эшчәнлегенең максатчан программалары, норматив-хокукый нигезе.

Ресурслар кытлыгы: яшьләр сәясәте учреждениеләренең челтәре җитәрлек үсеш алмау, яшьләр сәясәте учреждениеләренең материаль-техник базасы начар җиһазландырылу, кадрлар ресурслары (заманча тенденцияләр һәм һөнәри стандартлар таләпләре нигезендә белгечләрне өстәмә әзерләү яисә яңадан әзерләү таләп ителә).

Стратегия башлыча Баулы муниципаль районы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына, 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге, шул исәптән 35 яшькә кадәрге яшь гаиләләргә юнәлдерелгән.

Бүген «яшьләр» социаль төркеме төшенчәсе 14 яшьтән 35 яшькә кадәрге яшь рамкалары белән чикләнгән. 2021 елның 1 гыйнварына Баулы муниципаль районында 34 690 кеше яши иде, шуларның 22 145 е Баулы шәһәрендә һәм 12 545е авыл җирлекләрендә, 5 343 кеше - яшьләр. Еш кына бу төркем 14-17 яшьлекләр, 18-24 яшьлекләр, 25-30 яшьлекләр кластерына бүленә. Шулай ук яшьләрне мәктәп укучылары, студентлар, эшләүче яшьләр һәм яшь гаиләләргә бүлү кабул ителгән.

Моннан тыш, Стратегияне гамәлгә ашырганда яшьләрне социаль активлык критерие буенча төркемнәргә бүлүне исәпкә алу максатка ярашлы булыр: социаль һәм сәяси актив яшьләр; социаль-инертлы яшьләр; социаль-дезадаптив яшьләр; авыр тормыш хәлендә калган яшьләр.

## III. Стратегия максаты

Целью стратегии является – Баулы районы үсеше өчен яшьләрнең уңышлы төстә үз мөмкинлекләрен ачуга юнәлдерелгән хокукый, социаль-икътисадый һәм оештыру шартларын камилләштерү, шулай ук яшьләрнең җәмгыятькә уңышлы интеграцияләнүенә һәм ил тормышында аның ролен күтәрүгә ярдәм итү.

## IV. Өстенлекле юнәлешләр

Яшьләрне патриотик тәрбияләү – җәмгыятьтә социаль әһәмияткә ия булган гражданлык һәм патриотик кыйммәтләрне, карашларны, традицияләргә, мәдәнияткә, район тарихына хөрмәтне актуальләштерү, хәрби хезмәтнең абруен күтәрү.

Яшьләрнең иҗтимагый инициативаларына, яшьләр берләшмәләренә һәм формированиеләренә ярдәм итү һәм аларны координацияләү - яшьләрне социаль практикага җәлеп итү максатында һәм аларга үз-үзләрен үстерүнең потенциаль мөмкинлекләре турында мәгълүмат бирү, яшьләрнең гражданлык-патриотик, фәнни, иҗади һәм эшкуарлык активлыгына ярдәм итүне тәэмин итү.

Яшүсмерләр-яшьләрнең асоциаль һәм деструктив үз-үзен тотышларын беренчел профилактикалау - яшүсмерләр-яшьләр арасында сәламәт яшәү рәвешенең өстенлеген модельләштерү, яшьләрдә сәламәтлеккә сакчыл караш тәрбияләү, яшьләрнең экстремистик һәм террорчылык характерындагы хокукка каршы гамәлләрдә катнашуын булдырмау.

Яшьләр сәясәте учреждениеләрендә түбәндәге яшьләр иҗтимагый берләшмәләр эшли: «Без киләчәк яклы!» хәрәкәте», «Җиңү волонтерлары» бөтенроссия иҗтимагый хәрәкәте, Аграр яшьләр берләшмәсе, яшьләр парламенты, кибердружина.

Иҗтимагый берләшмәләргә ярдәм итү кысаларында яшьләр сәясәте учреждениеләре эшен оештырганда, без җәлеп ителгән яшьләрнең өлешен 14 - 30 яшьлекләр арасында 50 %ка кадәр, ә 2023 елга - 60 %ка кадәр арттырачакбыз.

Өстенлекле юнәлешне гамәлгә ашыру юллары:

- Баулы муниципаль районында яшьләр берләшмәләренә ярдәм итү буенча норматив-хокукый база эшләү;
- грант конкурсларында катнашу өчен яшьләр сәясәте өлкәсендә НКО булдыру;
- муниципаль программаларга яшьләр берләшмәләрен үстерү чараларын кертү;
- эшнең яңа формаларын кертү: нетворкинг, проект лабораториясе, коворкинг һәм башкалар;
- партнерлар даирәсен киңәйтү, креатив индустрияләр белән яңа элемтәләр урнаштыру һәм яшьләр эшкуарлыгын үстерү;
- яшьләрнең республика һәм төбәк конкурсларында катнашуы: «Ел лидеры», «Югарыга», «Кадрлар резервы», «іВолга», «Таврида» һ.б.

Социаль йогынты:

- Яшьләрдә патриотик, хезмәт, эшкуарлык, иҗади, сәяси һәм граждан активлыгы дәрәҗәсен күтәрү;
- Яшьләрне районның социаль-икътисадый, иҗтимагый-сәяси һәм социаль-мәдәни тормышында катнаштыру;
- Яшьләрне урамның тискәре йогынтысыннан аеру, сәламәт яшәү рәвешенә, сәламәтләндерүгә һәм аралашу даирәсен яхшыртуга җәлеп итү;
- Физик, психик һәм социаль иминлек өчен шартлар тудыру;
- Социаль әһәмиятле программаларда һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләренең проектларында эшләүче яшьләр санын арттыру;
- муниципаль идарәнең кадрлар резервын формалаштыру максатында иҗтимагый тормышның төрле өлкәләрендә социаль-актив кешеләрне ачыклау;
- Массакүләм мәгълүмат чараларында, интернет-сайтларда, телевидениедә, социаль челтәрләрдә яшьләр сәясәте турында мәгълүмати материал санын арттыру.

V. Юл картасы

I. Яшьләрне патриотик тәрбияләү

| Сроклар / Чаралар | 2021 ел | | | | 2022 ел | | | | 2023 ел | | | | нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | I | II | III | IV | I | II | III | IV | I | II | III | IV | |
| «2019-2021 елларга Баулы муниципаль районында яшьләрне патриотик тәрбияләү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру «2021 - 2025 елларга Баулы муниципаль районында яшьләрне патриотик тәрбияләү» муниципаль программасын эшләү | | | | | | | | | | | | | - патриотик берләшмәләр, клубларында торучы балалар һәм яшьләр санын арттыру (2025 ел - 15%ка);<br>- балаларны һәм яшьләрне патриотик юнәлештәге чаралар белән колачлауны арттыру (2025 ел - 13%ка);<br>- патриотик тәрбия өлкәсендә әзерләнгән белгечләр санын арттыру (2025 елга - 20 кеше, ел саен 4 кеше);<br><br>- яшьләрнең рухи-әхлакый культурасы дәрәҗәсен арттыру;<br><br>- граждан тәңгәллеге дәрәҗәсен күтәрү (2025 елга чаралар санын 10 %ка арттыру);<br><br>- Ватанны саклау бурычларын үтәүгә әзерлек дәрәҗәсен арттыру (2025 елга хәрби-кыр җыеннары кысаларында 500 хезмәткә чакырылу яшендәге егеткә әзерлек үтәрү);<br><br>– яшьләрне армиядә хезмәт итүгә әзерләү эшен камилләштерү (2025 елга чакырылыш яшендәге 650 егетне хәрби-исәпкә алу белгечлекләре |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | | буенча әзерләү);<br><br>– «ЮНАРМИЯ» Бөтенроссия иҗтимагый-патриотик хәрәкәте эшчәнлегенә балаларны һәм яшьләрне җәлеп итү (2025 елга яшь армиячеләр санын 15 %ка, ел саен 3 %ка арттыру). |
| «Я-гражданин России!»Яшьләр патриотик акциясе уздыру | | | | | | | | | | | | | Яшьләрнең гражданлык тәңгәллеге дәрәҗәсен күтәрү |
| Хәтер Маршы Республика чараларында катнашу һәм районда уздыру | | | | | | | | | | | | | Рухи-әхлакый культура дәрәҗәсен күтәрү һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү |
| Республика Хәтер Вахтасы чараларында катнашу | | | | | | | | | | | | | Яшьләрнең рухи-әхлакый культура дәрәҗәсен күтәрү һәм патриотик тәрбия бирү |
| «Ватанны яклауга әзер» чакырылу яшендәге егетләр арасында район бәйгесе үткәрү | | | | | | | | | | | | | Ватанны саклау бурычларын башкарырга әзерлек дәрәҗәсен арттыру |
| “Отчизны верные сыны” спортның хәрби-гамәли һәм техник төрләре буенча укучылар спартакиадасында катнашу һәм ярышлар үткәрү | | | | | | | | | | | | | Хәрби хезмәткә чакыруга кадәрге һәм чакырылу яшендәге яшьләрнең хәрби-гамәли спорт төрләрендә күнекмәләрен камилләштерү |
| Ватанны саклаучылар көненә багышланган оборона-массакүләм эш айлыгы үткәрү | | | | | | | | | | | | | Яшьләрнең гражданлык тәңгәллеге дәрәҗәсен күтәрү |
| БМР гомуми урта, урта һәм югары һөнәри белем бирү учреждениеләре | | | | | | | | | | | | | Хәрби хезмәткә чакыруга кадәрге һәм чакырылу яшендәге яшьләрнең хәрби- |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| арасында хәрби-гамәли муниципаль ярышлар үткәрү | | | | | | | | | | | | | гамәли спорт төрләрендә күнекмәләрен камилләштерү |
| «Хәрби хезмәткә чакырылу көне» патриотик акциясе үткәрү | | | | | | | | | | | | | Яшьләрне армиядә хезмәткә әзерләү эшен камилләштерү |
| «Аҗаган» хәрби-спорт уенының муниципаль этабын үткәрү | | | | | | | | | | | | | Хәрби хезмәткә чакырылу яшендәге яшьләрнең хәрби-гамәли спорт төрләрендә күнекмәләрен камилләштерү |
| «Георгий тасмасы» бөтенроссия акциясенең муниципаль этабын үткәрү | | | | | | | | | | | | | Балаларның һәм яшьләрнең патриотик юнәлештәге чаралар белән колачлануын арттыру |
| «Игелекле эшләр марафоны» бөтенроссия акциясе кысаларында чаралар үткәрү | | | | | | | | | | | | | Балаларның һәм яшьләрнең патриотик юнәлештәге чаралар белән колачлануын арттыру |
| «Җиңү салюты» Бөтенроссия халык иҗаты фестивалендә катнашу | | | | | | | | | | | | | Балаларның һәм яшьләрнең патриотик юнәлештәге чаралар белән колачлануын арттыру |
| «Җиңү волонтерлары» волонтерлык хәрәкәте эшчәнлеген камилләштерү | | | | | | | | | | | | | «Җиңү волонтерлары» волонтерлык хәрәкәте эшчәнлегенә җәлеп ителгән балалар һәм яшьләр саны арттыру |
| Советлар Союзы Герое генерал-майор Булатов истәлегенә багышланган кышкы чаңгы эстафетасын оештыру һәм үткәрү | | | | | | | | | | | | | Рухи-әхлакый культура дәрәҗәсен күтәрү һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү |
| Мәдәният һәйкәлләрен реставрацияләү үткәрү | | | | | | | | | | | | | Балаларның һәм яшьләрнең патриотик юнәлештәге чаралар белән колачлануын арттыру |

II. Яшьләр иҗтимагый башлангычларына, яшьләр берләшмәләренә һәм формированиеләренә ярдәм һәм координация

| Сроклар / Чаралар | 2021 ел | | | | 2022 ел | | | | 2023 ел | | | | результат |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | I | II | III | IV | I | II | III | IV | I | II | III | IV | |
| «2021 - 2025 елларга Баулы | | | | | | | | | | | | | - Программаны гамәлгә ашыру |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| муниципаль районында яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру | | | | | | | | | | | | | нәтиҗәсендә 2026 елга түбәндәгеләрне арттыру күздә тотыла:<br>- студентлар хезмәт отрядлары хәрәкәтендә катнашучы яшь кешеләрнең өлешен 6 %ка кадәр;<br>- ирекләләр эшчәнлегендә катнашучы яшьләрнең санын яшьләрнең гомуми санында 20,5 %ка кадәр җиткерү;<br>-талантлы яшьләргә ярдәм өлкәсендә башкарма хакимият органнары гамәлгә ашырган проектларга һәм программаларга җәлеп ителгән яшь кешеләрнең өлешен яшьләрнең гомуми санында 51,5 %ка кадәр;<br>-иҗтимагый-сәяси активлык һәм гражданлык компетентлыгы буенча чараларда катнашучы яшь кешеләрнең өлешен 6,2%ка кадәр;<br>-патриотик юнәлештәге чараларда катнашучы яшьләрне колачлауны 12 мең кешегә кадәр;<br>-талантлы яшьләргә ярдәм итүгә юнәлдерелгән конкурсларда катнашучы яшьләрне колачлауны 50 %ка кадәр;<br>- социаль тискәре күренешләрне профилактикалауга юнәлдерелгән чараларда катнашучы яшьләрне җәлеп итүне 14 %ка кадәр;<br>-яшьләр экстремизмын профилактикалау чараларына җәлеп |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | | ителгән яшьләр санын - 5 800гә кадәр;<br>- дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә Республика һөнәри осталык конкурсында катнашучы белгечләр санын 10 кешегә кадәр |
| Баулы муниципаль районы яшьләре арасында социаль әһәмиятле проектларның муниципаль конкурсы | | | | | | | | | | | | | - иң яхшы яшьләр инициативаларын ачыклау;<br>- Форум компанияләрендә катнашучылар санын арттыру |
| «Гайлә» гаилә иҗаты фестивале | | | | | | | | | | | | | -эшләүче яшьләрнең иҗади потенциалын ачу;<br>-фестивальдә катнашучылар санын арттыру |
| «PROFFI» яшь белгечләрнең фестиваль-конкурсы | | | | | | | | | | | | | форпостлыларның һөнәри үзбилгеләнеше, яшьләр арасында хокук бозуларның үсешен киметү |
| Яшь гражданнар форумы | | | | | | | | | | | | | - үсештә төп алымнарны булдыру ГМП юнәлешләрен үстерү, яшьләрне социаль әһәмияткә ия эшчәнлеккә җәлеп итү һәм дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру. |
| Яшь эшмәкәрләр форумы | | | | | | | | | | | | | - төрле эшчәнлек өлкәләреннән уңышлы, максатчан эшкуарлар бергәлеге булдыру<br>- бизнесны алга җибәрү өчен тәҗрибә, идеяләр, табышлар алмашу |

**I.** Яшүсмерләр-яшьләр арасында асоциаль һәм деструктив тәртипне беренчел профилактикалау

| Сроки / Мероприятия | 2021 ел | | | | 2022 ел | | | | 2023 ел | | | | Результат |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | I | II | III | IV | I | II | III | IV | I | II | III | IV | |
| Чаралар планнарын эшләү һәм аларны муниципаль программаларга кертү:<br>«2021 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында халыкның наркотизацияләнүен профилактикалау»;<br>«2020-2023 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау» муниципаль программасы.»;<br>«2019 - 2023 елларга Баулы муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасы.»;<br>2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау комплекслы программасы | | | | | | | | | | | | | Баулы муниципаль районының яшүсмерләр-яшьләр арасында профилактика субъектларының ведомствоара хезмәттәшлеге нигезендә асоциаль һәм деструктив тәртипне нәтиҗәле профилактикалау системасын булдыру |
| Баулы муниципаль районы яшүсмерләренә һәм яшьләренә психолог-педагогик ярдәм күрсәтү (Баулы муниципаль районы яшьләр сәясәте психологының индивидуаль һәм төркем белән эше) | | | | | | | | | | | | | БМР үсмерләренең һәм яшьләренең психик сәламәтлеген саклап калу, шәхси үсеш коррекциясе; үсмерләрнең һәм яшьләрнең социаль адаптациясе |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | | |
| «Большая перемена» проектын гамәлгә ашыру | | | | | | | | | | | | | Балаларның һәм яшүсмерләрнең «аерым игътибар төркеменең» социализациясе һәм уңышлы җайлашуы, проектта катнашучылар төркемнәрендә стигматизация нейтральләштерү, әлеге категория белән эшләүче балалар һәм педагогларның эмоциональ торышын тотрыкландыру |
| «Дворовая лига» проектын гамәлгә ашыру | | | | | | | | | | | | | БМР яшүсмерләрендә һәм яшьләрендә сәламәтлнене саклый торган караш, кризислы ситуацияләрдә һәм куркыныч ситуацияләрдә психологик тотрыклылык күнекмәләре формалаштыру; сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыру |
| «Сәламәт гаилә» проектын гамәлгә ашыру | | | | | | | | | | | | | Көндәлек гаилә тормышына сәламәт яшәү рәвеше кертүгә ярдәм итә торган спорт-савыктыру эшенең бербөтен системасын булдыру. |
| «Медиацентр» программасын гамәлгә ашыру | | | | | | | | | | | | | Яшүсмерләрнең шәхси үсеше, үзлегеннән белем алу һәм иҗади хезмәте, аларның үзбилгеләнеше, ялы өчен оптималь шартлар тудыру. |
| | | | | | | | | | | | | | Баулы шәһәренең җәйге балалар ишегалды мәйданчыкларында, паркларда, скверларда социаль |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Күңелле ишегалды» проектын гамәлгә ашыру | | | | | | | | | | | | | тискәре күренешләрне кисәтүгә, рухи-әхлакый, патриотик кыйммәтләр тәрбияләүгә, сәламәт яшәү рәвешен якынайтуга, дөньяга карашын киңәйтүгә юнәлдерелгән нәтиҗәле һәм файдалы ял вакытын оештыру |
| Авыр тормыш хәлендәге гаиләләрдәге яшүсмерләр белән «Без бергә» проектын тормышка ашыру. | | | | | | | | | | | | | Күпмилләтле җәмгыять кыйммәтләре, гомумроссия гражданлык тәңгәллеге һәм мәдәни танып белү кыйммәтләре нигезендә толерант мохит өчен шартлар тудыру, Баулы муниципаль районының кеше хокуклары һәм ирекләре тигезлеген тәэмин итү. |